ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

«20» 04 2020 ел Яр Чаллы № 1439

2020-2022 елларга Тукай муниципаль районының берләштерелгән бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү чаралары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районының берләштерелгән бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, 2020-2022 елларга Тукай муниципаль районының бюджеттан тыш өстәмә чыганакларын эзләү буенча чаралар исемлеген расларга.
2. Исемлек чараларын үтәү өчен җаваплы җирле үзидарә органнарына, тармак бүлекләренә, 2021 елның 1 февраленнән башлап, ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленнәндә соңга калмыйча, Тукай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2020-2022 елларга Тукай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү буенча чаралар исемлеген үтәү турында хисаплар җибәрергә.
3. Әлегекарар Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны районның финанс-бюджет палатасы рәисе Л.Н. Хужагалиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов